АГЕНТСТВО
ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ
АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

« 25 » ноябрь 2017 г. № 33

Казан шәһәре

**Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйгесе турында**

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең гражданлык хезмәте турында» Законына, 2005 елның 1 февралендә кабул ителгән 112 нче номерлы «Россия Федерациясендәге гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү буенча бәйгесе турында» РФ Президенты Боерыгына, 2003 елның 16 гыйнварында кабул ителгән 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» Законына ярашып

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү буенча бәйге уздыру өчен төзелгән комиссиянең эш тәртибен һәм вакытын билгеләү (1нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйге уздыруның методикасын раслау (2нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының боерыклары үз

көчен җуя:

2014елның 19 маендагы 76/2лс номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйге турында»;

2014елның 19 маендагы 76/2лс номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйге турында» 2016 елның 16 декабрендәге 41 нче номерлы «Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының боерыгына үзгәрешләр кертү турында».

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И. Миңнуллина

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгы
Боерыгы нигезендә
2017 елның 25 ноябрендә
33 нче номер белән расланган
1нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар ревзервына кертелү) буенча бәйге уздыру өчен төзелгән комиссиянең эш тәртибе һәм вакыты**

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү буенча бәйге (кадрлар резервына кертелү) (алга таба – бәйгенең комиссиясе) үз эшчәнлеген даими башкара, ул рәис, рәиснең урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2. Бәйге комиссиясенең эшчәнлеге белән җитәкчелек итү комиссия рәисенә йөкләнә. Комиссия рәисе вакытлыча бу вазыйфаны үти алмаганда (авыру, командировкада булу, отпускка китү сәбәпле) комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итү бәйге комиссиясенең рәис урынбарасына йөкләнә.

3. Бәйге комиссиясенең эшчәнлеген тәэмин итүне (гаризалар кабул итү һәм теркәү, эшләрне тәртипкә салу, бәйге комиссиясе утырышларында беркетмә алып бару) кадрлар белән эшләү өчен җаваплы Агентлык хезмәткәре башкара, ягъни – бәйге комиссиясенең секретаре. Бәйге комиссиясенең секретаре Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итәргә

(кадрлар резервына кертелергә) (алга таба – гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфа) яраклы булырга мөмкин кандидатларны бәяләүдә катнаша.

4. Бәйге комиссиясе утырышы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйге (алга таба – бәйге) уздыру турында Агентлык җитәкчесе Боерык игълан иткән очракта уздырыла.

5. Бәйге комиссиясе утырышы гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага (кадрлар резервына кертелүгә) икедән дә ким булмаган кандидат дәгъва иткән очракта үткәрелә.

5. Бәйге комиссиясе комиссия әгъзаларының өчтән икесе катнашкан очракта хокуклы санала. Утырыш гражданлык хезмәте вазыйфаларында торучы комиссия әгъзалары катнашында гына уздырылырга тиеш түгел. Бәйгене уздыру нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карарлары утырышта булган әгъзаларның гади күпчелеге тавышына нигезләнеп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда бәйге комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч исәпләнә.

6. Бәйге барышында бәйге комиссиясе кандидатларны белеме, гражданлык, йә булмаса башка төр дәүләт хезмәтендә булуы, яисә икенче төрле хезмәт башкаруы турындагы үзләре тәкъдим иткән документлар, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе федераль законнары һәм башка хокукый актларга каршы килмәгән бәйге процедуралары ярдәмендә бәяли ала. Соңгыларына шәхси әңгәмә, анкета тутырту, төркемләп дискуссияләр уздыру, реферат яздыру, сораулар буенча тестлар үткәрү керә, болар барысы да кандидатларның үзләре дәгъва иткән буш (вакант) дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына туры килү-килмәүләрен ачыклар өчен кирәк.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә бәйге комиссиясе дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасы һәм вазыйфа буенча каралган эш регламенты таләп иткән тиешле квалификация үзенчәлекләрен күздә тотып эш итә, моннан тыш комиссия Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте буенча башка кайбер кагыйдәләрен дә исәпкә ала.

7. Бәйге комиссиясенең карары гражданлык хезмәтенә дәгъва итүче (кадрлар

резервына кертелүче) кандидат үзе югында кабул итеЛә һәм ул аның гражданлык хезмәтенә билгеләнүенә (кадрлар резервына кертелүенә) яисә кире кагылуына нигез булып тора.

Бәйге комиссиясе, моннан тыш, гражданлык хезмәте вазыйфасына дәгъва иткән, әмма җиңеп чыкмаган кандидатны, югары һөнәри һәм шәхси сыйфатларын исәпкә алып, Агентлыкның кадрлар резервына кертергә дә тәкъдим итәргә мөмкин.

8. Бәйге комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашкан әгъзалар тарафыннан кул куелган карар буларак теркәлә.

9. Бәйге нәтиҗәләре буенча яллаучының вәкиле тарафыннан гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына дәгъва итү буенча бәйгедә кемнең җиңүе хакындагы акт чыгарыла, җиңүче белән хезмәт контракты төзелә.

Әгәр Агентлык тарафыннан дәүләт гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына дәгъва итеп, җиңеп чыкмаган кандидатны кадрлар резервына кертү турында карар кабул ителсә, билгеләнгән вәкил ризалыгына нигезләнеп, Агентлык тарафыннан аны гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына тәңгәл булган гражданлык хезмәте төркеменә кертүләре турында Боерык чыгарыла.

10. Кандидат Россия Федерациясе закончалыгы нигезендә бәйге комиссиясенең карарына шикаять бирә ала.

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш агентлыгы
Боерыгы нигезендә
2017 елның 25 ноябрендә
33 нче номер белән расланган
2нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйге уздыруның методикасы**

## Гомуми кагыйдәләр

1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә буш (вакант) вазыйфага дәгъва итү (кадрлар резервына кертелү) буенча бәйге уздыруның түбәндәге методикасы (алга таба – методика) Инвестицион үсеш агентлыгындагы (алга таба – Агентлык) бәйге уздыру шартлары һәм тәртибен билгели.

2. Бәйгене уздыруның төп бурычлары:

- Россия Федерациясе гражданнарын дәүләт гражданлык хезмәтенә урнашырга мөмкинлек бирүче тигез конституцион хокуклар белән тәэмин итү,

- дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләрен бәйге нигезендә үз һөнәри өлкәсендә үсеш белән тәэмин итү,

- Агентлыкның кадрлар резервын дәүләт гражданлык хезмәтенә ярардай кадрлар белән тәэмин итү.

3. Бәйге дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасына дәгъва итүче (кадрлар резервына кертелүче) кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү, аларның бу вазыйфа өчен тиешле таләпләргә җавап бирүен ачыклау һәм җиңүчене билгеләүдән гыйбарәт.

## Бәйгене уздыруны оештыру

4. Бәйге башка гражданлык хезмәткәре биләп тормаган буш (вакант) урын барлыгы ачыклангач, Агентлык җитәкчесе карары белән игълан ителә. Буш (вакант) урынга кандидат 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданлык хезмәте турында» Федераль законның 22 маддәсенә ярашып, Агентлык тарафыннан оештырылган бәйге нигезендә һәм Агентлык Боерыгы буенча билгеләнә.

5. Бәйге Агентлыкта үткәрелми:

а) Агентлыкта гражданлык хезмәте вазыйфасының «җитәкче» һәм «ярдәмче (киңәшче)» категорияләрендәге билгеле бер вакыт аралыгында үтәлә торган вәкаләтләргә хезмәткәр билгеләү таләп ителгәндә;

б) билгеле бер вакыт аралыгын үз эченә алган контракт күздә тотылганда;

в) гражданлык хезмәте вәкилен 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законының 28 нче маддәсендәге 2 нче өлеш, 31 нче маддәсендәге 1 нче өлеш, 60.1 нче маддәсендәге 9 нчы өлешләрдә каралган очраклар буенча башка гражданлык вазыйфасына билгеләгәндә;

д) гражданлык хезмәте резервына кертелгән хезмәткәрне (гражданинны)

гражданлык хезмәтенә билгеләгәндә.

6. Бәйге үткәрелмәскә дә мөмкин:

а) Агентлык Боерыгы буенча расланган һәм башкарганда дәүләт дәрәҗәсендәге серләр белән эш итүне күздә тоткан гражданлык вазыйфасына хезмәткәр билгеләгәндә;

б) Агентлык Боерыгы буенча расланган һәм гражданлык хезмәтенең кече вазыйфаларына караган очраклар күздә тотылганда.

7. Бәйгедә Россия Федерациясенең 18 яшен тутырган, Россия Федерациясе телләрен белгән һәм Россия Федерациясе закончалыгының дәүләт гражданлык хезмәте буенча дәүләт гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасы таләпләренә җавап биргән теләсә кайсы гражданы катнаша ала.

Граждан хезмәткәре, бәйге узганда нинди вазыйфада булуына карамастан, гомуми хокуклар нигезендә бәйгедә катнаша ала.

8. Бәйге ике этаптан гыйбарәт:

Беренче этапта дәүләт органының сайтында һәм дәүләт гражданлык хезмәтенең «Интернет» мәгълүмати-телебагланышлар дәүләт мәгълүмати системасында бәйгедә катнашыр өчен документлар кабул ителүе турында игълан урнаштырыла. Шулай ук бәйге турында да игълан эленә: гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасы, әлеге вазыйфага дәгъва итәр өчен нинди һөнәри шартлар таләп ителүе, гражданлык хезмәтен узу шартлары, әлеге Кушымтаның 9 нчы пунктында күрсәтелгән тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, документларны кабул итү вакытының кайчан төгәлләнүе, күздә тотылган бәйгенең узу вакыты, аны уздыру урыны һәм вакыты, башка мәгълүмати материаллар. Бәйгедә катнашу өчен кирәкле документларны кабул итү һәм бәйгенең үзе хакындагы мәгълүматларны шулай ук вакытлы матбугат битләрендә дә урныштырырга мөмкиннәр.

9. Бәйгедә катнашырга теләк белдергән гражданин дәүләт органына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан расланган форма буенча

тутырылган һәм култамгасы куелган анкетаны, фотография булуы мәҗбүри;

в) паспорт нөсхәсе яисә аны алыштыручы документны (әлеге төр документ бәйгедә катнашырга килгәч тәкъдим ителә);

г) тиешле һөнәри белемгә ия булуы турындагы һәм эш стажын, квалификациясен раслаучы документ;

- нотариус яисә элеккеге эш урынындагы (хезмәтендәге) кадрлар бүлеге тарафыннан расланган эш кенәгәсенең нөсхәсе (хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрү очрагына туры килмәгәндә), йә булмаса гражданинның моңарчы кайда хезмәт куйганын билгеләүче башка төр документ;

- белем һәм квалификация турындагы документларның нөсхәсе, шулай ук гражданинның шәхси теләге буенча – өстәмә белем, фәнни дәрәҗә алу турындагы кадрлар бүлеге яисә элеккеге эш урыны (хезмәте) раслаган документлар нөсхәсе;

д) гражданинның гражданлык хезмәтен башкаруга комачау итәрдәй авыруы булмау турындагы табиб күрсәтмәсе;

е) 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законы, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты Боерыгы һәм Россия Федерациясе Хакимияте карары нигезендә таләп ителгән башка документлар.

10. Агентлыкның бәйгедә катнашырга теләк белдергән граждан хезмәткәре гаризаны җитәкче исеменә бирә.

Бәйгедә катнашырга теләге булган башка дәүләт органында вазыйфа башкаручы граждан хезмәткәре Агентлыкка гаризаны Агентлык җитәкчесе исеменә, үз кулы белән тутырып, култамгасын куеп һәм үзе вазыйфасын башкарган дәүләт органының кадрлар хезмәтеннән раслатып тапшыра, Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан расланган анкетаны да, фотографиясен беркетеп, бергә урныштыра.

11. Методиканың 9, 10 нчы пунктларында күрсәтелгән документлар «Интернет» мәгълүмати-телебагланыш челтәрендә һәм Татарстан Республикасы Хакимиятенең рәсми порталындагы Агентлыкның рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru), шулай ук «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте

кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмати системасында урнаштырылганнан соң, югарыда күрсәтелгән электрон системаны кулланып, 21 каендарь көн дәвамында юллана.

Документларны электрон рәвештә тәкъдим итүнең тәртибе Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан билгеләнә.

Документларны тиешле вакытта тапшырмау, йә булмаса, җитди сәбәпләрдән тыш, өлешләп, яисә тутыру тәртипләренә хилафлык кертеп тапшыру гражданинга (граждан хезмәткәренә) аларның кире кагылуы турында игълан итүгә сәбәп була ала.

Документларны тиешле вакытта тапшырмау, йә булмаса өлешләп, яисә тутыру тәртипләренә хилафлык кертеп тапшыруда җитди сәбәпләрнең булуы яллаучының вәкиленә (бәйге комиссиясенең рәисенә) аларны кабул итүне озайтуны оештырырга мөмкинлек бирә.

12. Гражданин (граждан хезмәткәре) ризалыгы буенча ул дәгъва иткән вазыйфаны үтәгәндә таләп ителә торган дәүләт серләрен яисә закон тарафыннан саклана торган башка мәгълүматларны куллану өчен рөхсәт булдыру процедурасы үткәрелә.

Гражданин тарафыннан Агентлыкка тапшырылган мәгълүматлар тикшерелә. Электрон рәвештә тәкъдим ителгән мәгълүматлар Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан расланган тәртиптә автоматик тикшерүгә дучар ителә.

Граждан хезмәткәре тәкъдим иткән мәгълүматлар ул гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфалары арасыннан (кадрлар резервына кертелү) үзе биләгән хезмәттән югарырак төркеменә дәгъва иткән очракта тикшерелә.

13. Гражданин (граждан хезмәткәре) бәйгедә катнашуга үзе дәгъва иткән гражданлык хезмәтенең (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәтләренең) һөнәри-квалификацион таләпләренә җавап бирмәгән очракта, шулай ук Россия Федерациясе закончалыгының дәүләт гражданлык хезмәтенә кабул итү һәм аны башкару буенча теркәлгән чикләмәләренә караган очракта кертелми.

14. Бәйгенең икенче этабын уздыру турындагы карарны, аның вакытын һәм урынын комиссия рәисе гражданлык хезмәте вазыйфасына (кадрлар резервына

кертелүгә) дәгъва итүчеләрнең мәгълүматлары тикшерелгәч, шулай ук, таләп ителгән очракта, дәүләт һәм башка саклауны сораган серләр белән эш итүгә рөхсәт теркәлгәч кенә кабул итә. Бәйгенең икенче этабы бәйгедә катнашу өчен документлар кабул ителү тәмамланганнан соң 30 календарь көн узганнан соң үткәрелә, әгәр дәүләт һәм башка саклауны сораган серләр белән эш итүгә рөхсәт таләп ителә икән, бәйгенең икенче этабын билгеләүне яллаучының вәкиленә (бәйге комиссиясе рәисенә) тапшыралар.

Тикшерү вакытында Россия Федерациясе федераль законнары яисә башка норматив хокукый актларга каршы килә торган шартлар табылса, гражданлык хезмәтенә дәгъва итүче кандидатка бәйге комиссиясенең секретаре аның ни өчен икенче этапка уза алмавы хакында хат аша хәбәр итә. Гражданин бәйгедә катнашыр өчен документларын электрон рәвештә тәкъдим итсә, аңа бу хәбәрне дәүләт хезмәте мәгълүмати система өлкәсендә кулланылганча, квалификацияле электрон култамга белән нигезләп, электрон рәвештә юллыйлар.

15. Бәйгедә катнаша алмаган дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфасына (кадрлар резервына кертелү) дәгъва итүче претендент әлеге карарга каршы Россия Федерациясе законлылыгына таләпләренә туры килгәнчә шикаять бирә ала.

Агентлыкның кадрлар резервына 24.07.2014 79-ФЗ номерлы «Дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законының 57 маддәсенең 1 өлеше, 2 нче, 3 нче пунктларында, йә булмаса 59.1. маддәсендәге 2 нче, 3 нче пунктларында каралган дисциплина буенча шелтәләргә тарыган дәүләт хезмәткәре кертелә ала.

16. Бәйге комиссиясе секретаре бәйгенең икенче этабына 15 календарь көн кала үзләренең рәсми сайтында һәм «Интернет» дәүләт хезмәте дәүләт мәгълүмати система рәсми сайтында бәйгенең алга таба кайда, кайсы вакытта узачагын игълан итә, монда шулай ук алга таба катнашу хокукына ия булган гражданнарның (граждан хезмәткәрләренең) исемлеге (алга таба – кандидатлар) урнаштырыла. Шуннан соң кандидатларга хат аша тиешле хәбәр җиткерелә, документларын электрон рәвештә тәкъдим итүчеләргә, бу хәбәрне дәүләт хезмәте мәгълүмати система өлкәсендә кулланылганча, квалификацияле электрон култамга белән нигезләп, электрон рәвештә юллыйлар.

17. Бәйге дәвамында кандидатлар дәгъва итә торган гражданлык хезмәте вазыйфасының буш (вакант) урынына һөнәри яктан туры килүче зат табылмаса, Агентлыкның җитәкчесе бәйгене тагын бер кат кабатлау турында карар кабул итәргә хокуклы.

18. Бәйге барышында бәйге комиссиясе кандидатларны белеме, гражданлык яисә башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, бүтән өлкәдә хезмәт куюы, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закончалыгына каршы килми торган методлары буенча сайлый. Монда тестлар уздыру да, гражданлык хезмәтенең кандидат дәгъва иткән вазыйфасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфаларына) карый торган бурычлар хакында шәхси әңгәмә дә керә.

19. Агентлыкта гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфаларына) дәгъва итүче кандидатлар белән үткәрелә торган тестлар Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфаларына) дәгъва итүчеләр өчен махсус әзерләнгән һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган Тестлар уздыру методикасы нигезендә башкарыла.

20. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә бәйге комисиясе дәүләт гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына дәгъва итүчеләрнең тиешле квалификация таләпләренә җавап бирүләрен, әлеге вазыйфага хезмәт регламентының башка кагыйдәләре буенча туры килүләрен, шулай ук Россия Федерациясе закончалыгы тарафыннан дәүләт гражданлык хезмәтенә куйган башка таләпләр буенча яраклы булуларына игътибар итә.

21. Бәйге комиссиясенең бәйгене уздыру нәтиҗәләре буенча карарлар кандидат үзе югында утырышта катнашкан әгъзалар тарафыннан ачык рәвештә күпчелекнең тавыш бирүе ысулы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта хәлиткеч тавышны бәйге комиссиясе рәисе бирә.

22. Бәйге комиссиясе кабул иткән карар гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына кандидатны кабул итү яисә кире кагу өчен нигез булып тора, кайбер очракта – бәйгедә җиңгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) Агентлыкның кадрлар резервына кабул итү дә.

Бәйге комиссиясе шулай ук гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына бәйгедә катнашып, җиңеп чыкмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны да Агентлыкның кадрлар резервына тәкъдим итәргә хокуклы.

**Йомгак**

23. Бәйге нәтиҗәләре буенча Агентлык гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына бәйгедә җиңүчене билгели һәм аның белән хезмәт контракты төзү турында Боерык чыгара.

Бәйге комиссиясе гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасына дәгъва итүче кандидат җиңеп чыкмаган очракта аны Агентлыкның кадрлар резервына тәкъдим итә икән, күрсәтелгән зат тарафыннан ул Агентлыкның гражданлык хезмәтенең буш (вакант) вазыйфасының бәйге буенча дәгъва иткән төркеменә кертеләчәк, дигән Боерык чыгарыла.

24. Бәйгенең нәтиҗәләре турындагы хәбәр ул тәмамланганнан соң 7 көн эчендә кандидатларга хат аша җибәрелә. Документларын электрон рәвештә тәкъдим итүче кандидатларга хәбәрне, «Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте составы һәм кадрлар белән идарә итү бердәм мәгълүмати системасы» (http://www.gossluzhba.gov.ru) федераль дәүләт мәгълүмати системасына нигезләнеп, дәүләт хезмәте мәгълүмати системасы өлкәсендә кулланылганча, квалификацияле электрон култамга белән раслап, электрон рәвештә юллыйлар. Бәйге нтиҗәләре турындагы мәгълүмат шул ук вакытта «Интернет» мәгълүмати-телебагланышлы сайтында, Татарстан Республикасы Хакимияте рәсми порталының Агентлык рәсми сайтында (http://tida.tatarstan.ru) һәм билгеләнгән мәгълүмати башка мәгълүмати системада урнаштырыла.

25. Бәйгедә катнаша алмый дип табылган гражданлык хезмәтенең буш

(вакант) вазыйфасына (кадрлар резервына кертелүгә) претендентларның һәм бәйгедә катнашкан кандидатларның документлары аларның үзләренә бәйге тәмамланганнан соң өч ел дәвамында махсус хат рәвешендә тәкъдим ителгән гариза нигезендә кайтарыла ала. Аңа кадәр документлар дәүләт органы архивында саклана, соңыннан юк ителә. Бәйгедә катнашу өчен электрон рәвештә тәкъдим ителгән документлар шулай ук өч ел дәвамында саклана, аннан соң алар да юкка чыгарыла.

26. Бәйгедә катнашу буенча чыгымнарны (бәйге уза торган урынга бару һәм кайту, торакка урнашу, яшәү, элемтә чараларын куллану һ.б.) кандидатлар үзләре каплый.